| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 13.04.2022 | г. Казань | № 38-2/т-2022 |

«Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 13 апрелендәге 8-ПР номерлы идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә, әлеге карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә максималь тарифлар әлеге карар үз көченә кергән көннән башлап 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү турында» 10.03.2021 № 31-4/т-2021 карары гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.04.2022 № 38-2/т-2022
карарына кушымта

«Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдалануда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| | Хезмәт күрсәтү төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Әлмәт маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 23,49 |
| 2. | Түбән Кама маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 17,73 |
| 3. | Түбән Кама нефть базасы кишәрлеге буенча 1 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 3,60 |
| 4. | Алан (Алан ст.) маневрлы районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу (Алан ст.) | 1 тонна | 48,07 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан йөк ташуның факттагы авырлыгы өчен алына.

3. Йөк ташу буенча түләү алу өчен ераклык төгәл санга түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге